ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**“Вөждан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында”**
**Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 25 сентябрендә
кабул ителде

**1 статья**

“Вөждан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында” 1999 елның 14 июлендәге 2279 номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1999, № 8 (II өлеш); 2001, № 12; 2004, № 2 (I өлеш); 2008, № 6; 2010, № 3; 2011, № 6 (I өлеш); 2012, № 8; 2013, № 7; 2014, № 6 (II өлеш), № 7; 2015, № 1 – 2, № 4, № 7 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 статьяның 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
“1. Татарстан Республикасында вөждан иреге һәм дин тоту иреге, шул исәптән теләсә кайсы динне индивидуаль яисә башкалар белән бергә тоту яисә берсен дә тотмау, гыйбадәт кылулар, башка дини йолалар һәм тантаналар үткәрү, дингә өйрәтү һәм дини тәрбия бирү, дини һәм башка инануларны ирекле сайлау һәм үзгәртү, дин тоту һәм тарату, шул исәптән дини берләшмәләр төзеп, шулар нигезендә эш итү хокукы гарантияләнә.”;

2) 6 статьяда түбәндәге эчтәлекле $3^1$ пункт өстәргә:
“$3^1$. Дини берләшмәләр Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә дини берләшмәләрнең эчке таләпләре белән билгеләнә торган рәвешләрдә үзенең тарафдарларын дингә өйрәтергә һәм аларга дини тәрбия бирергә хокуклы. Дингә өйрәтү һәм дини тәрбия бирү белем бирү эшчәнлеге булып тормый.”;

3) 9 статьяда:
а) 1 пунктта түбәндәге эчтәлекле яңа икенче җөмлә өстәргә: “Дини төркемгә Россия Федерациясе гражданнары керә, шулай ук Россия Федерациясе территориясендә даими һәм законлы нигезләрдә яшәүче башка затлар керергә мөмкин.”;

б) 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“2. Дини төркемнең эшли башлавы турында “Вөждан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында” 1997 елның 26 сентябрендәге 125-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән тәртиптә дини оешманы дәүләт теркәвенә алу хакындагы карарны кабул итәргә вәкаләтле органга хәбәр ителергә тиеш.

Дини төркем дини оешманы дәүләт теркәвенә алу хакындагы карарны кабул итәргә вәкаләтле органга иң соңыннан хәбәр ителгән көннән алып кимендә өч елга бер мәртәбә үз эшчәнлеген дәвам итү турында хәбәрнамә бирә.”;

4) 11 статьяның 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“1. Унсигез яшенә җиткән һәм бер урында йә бер шәһәр яисә авыл җирлегендә даими яшәүче кимендә ун Россия Федерациясе гражданы җирле дини оешманың гамәлгә куючылары була алалар.”;

5) 30 статьяның 4 пунктында:

а) икенче һәм өченче абзацларны үз көчләрен югалткан дип танырга;

б) түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

“Бер үк диндәге үзәкләштерелгән дини оешма структурасына керми торган җирле дини оешмалар дәүләт теркәвенә алу көненнән алып (төзелгәндә) ун ел дәвамында әлеге Законның 6 статьясындагы 3 һәм 4 пунктларында (балигъ булган гражданнарга карата өстәмә гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларын төзү хокукыннан тыш), 19 статьясындагы 4 пунктында, 22 статьясындагы 2 пунктында (массакүләм мәгълүмат чараларына карата), “Вөждан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында” 1997 елның 26 сентябрендәге 125-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясындагы 5 пунктында һәм 20 статьясындагы 2 пунктында каралган хокуклардан файдаланмыйлар, шулай ук үзәкләштерелгән дини оешманың гамәлгә куючылары булырга хокуксыз булалар.”.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2015 елның 8 октябре
№ 75-ТРЗ